ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2021 г.Лениногорск № 1254

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 21 июнендәге 582/1 номерлы карары белән расланган күчмә сәүдә алып бару өчен махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 1662 номерлы карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 21 июнендәге 582/1 номерлы карары белән расланган күчмә сәүдә алып бару өчен махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

4.2 пунктта:

икенче абзацта «казаныш турында хисап» сүзләреннән соң «әһәмияте» сүзе белән тулыландырырга;

өченче абзацта «финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында» сүзләреннән соң «(кварталга бер тапкырдан да ким түгел)» сүзләре белән тулыландырырга;

5 пунктта «контроль» сүзен «контроль (мониторинг) сүзләренә алыштырырга».

5.2 пунктта:

беренче абзацта «контроль» сүзен «контроль (мониторинг)» сүзләренә алыштырырга;

«а» пунктчасында «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

Түбәндәге эчтәлектәге «а_1» пунктчасы белән тулыландырырга:

«а_1) субсидия бирү (контроль нокта) нәтиҗәләренә ирешүне, килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәмамлау фактын чагылдыра торган вакыйгалардан чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг уздыру турында таләп;».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Руководитель З. Г. Михайлова

Л.М.Галимова
5-44-72